БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«02» 08 2024 ел № 202

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2020 елның 06 мартындагы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә яшәүче торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу (кую) буенча торак комиссиясен төзү турындагы» 116 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Балтач районы прокуратурасының 2024елның 26 июнендәге 02-08-01-2024/Прдп276-24-20920011 номерлы протестын карап, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2020 елның 06 мартындагы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә яшәүче торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу (кую) буенча торак комиссиясен төзү турындагы» 116 номерлы карарына, преамбулага «социаль файдалану» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасының 2004 елның 27 декабрендәге «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турындагы» 69-ТРЗ номерлы Законы белән» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2020 елның 06 мартындагы 116 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә яшәүче гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу (кую) буенча торак комиссиясен төзү турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 1.1 пунктында «социаль файдаланудагы»,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасының 2004 елның 27 декабрендәге «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турындагы » 69-ТРЗ номерлы Законы белән»,» сүзләрен өстәргә.

2.2. 1.2 пунктында «закон» сүзен «Татарстан Республикасы законнары» сүзләренә, «бу закон белән» сүзләрен «бу законнар белән» сүзләренә алмаштырырга;

2.3. 2.1 пунктында «ихтыяҗ туган саен» сүзләрен «расланган план нигезендә» сүзләренә алмаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов